**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Перечня должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственным гражданским служащим Республики Татарстан запрещается открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами

В соответствии с подпунктом «и» пункта 1 части 1 статьи 2 Федерального закона от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами» и пунктом 2 Указа Президента Российской Федерации от 8 марта 2015 года № 120 «О некоторых вопросах противодействия коррупции» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемый Перечень должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственным гражданским служащим Республики Татарстан запрещается открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами.

2. Руководителям государственных органов Республики Татарстан:

а) в месячный срок утвердить в соответствии с перечнем должностей, утвержденным настоящим Указом, перечни конкретных должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан в соответствующих государственных органах Республики Татарстан, при замещении которых государственным гражданским служащим Республики Татарстан запрещается открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами;

б) ознакомить заинтересованных государственных гражданских служащих Республики Татарстан с перечнями, предусмотренными подпунктом «а» настоящего пункта;

в) представить в Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан и Управление Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики перечни, утвержденные в соответствии с подпунктом «а» настоящего пункта, в трехдневный срок со дня утверждения, а в последующем, при внесении в них изменений, представлять уточненные перечни в недельный срок после внесения изменений.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
08 июня 2015 года
№ УП-542

Утвержден
Указом Президента
Республики Татарстан

от «08» июня 2015 года

№ УП - 542

**Перечень**
**должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, при замещении которых государственным гражданским служащим Республики Татарстан запрещается открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами**

1. Должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Аппарате Президента Республики Татарстан, Аппарате Государственного Совета Республики Татарстан, Аппарате Кабинета Министров Республики Татарстан, центральных аппаратах органов исполнительной власти Республики Татарстан, аппарате Конституционного суда Республики Татарстан, представительствах Республики Татарстан в Российской Федерации и субъектах Российской Федерации, отнесенные Реестром должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, утвержденным Указом Президента Республики Татарстан от 18 января 2006 года № УП-9 «О Реестре должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан», к высшей группе должностей.

2. Должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, исполнение обязанностей по которым предусматривает допуск к сведениям особой важности.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 өлеше 1 пунктының «и» пунктчасы һәм Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә:
а) әлеге Указ нигезендә расланган вазыйфалар исемлеге буенча Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген 1 ай эчендә расларга;

б) кызыксынган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге пунктның «а» пунктчасында каралган исемлек белән таныштырырга;

в) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә өч көн эчендә әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә расланган исемлекләрне тапшырырга, аларга үзгәрешләр кергән очракта, ачыкланган исемлекләрне үзгәрешләр керткәннән соң бер атна дәвамында бирергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 08 июнь
№ ПУ-542

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 08 » июнендәге
ПУ- 542 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, алар дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын билгәндә, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестрында вазыйфаларның югары төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы Президенты Аппаратындагы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратындагы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратындагы, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының үзәк аппаратларындагы, Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратындагы, Россия Федерациясендә һәм Россия Федерациясе субъектларында Татарстан Республикасы вәкиллекләрендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфа билгәндә аеруча мөһим мәгълүматлар белән эшләү күздә тотылган вазыйфалары.

———